*Туган халкыңа хезмәт ит!*

http://alga-rb.ru

# Алга

№ 12 (11045)
Җомга
10 февраль
2017 ел.

12+

Башкортстан Республикасы Борай районы муниципаль районының иҗтимагый-сәяси гәзите

Гәзит 1930 елның 19 февраленнән чыга.

Сатуда бәясе ирекле

• СОВЕТ УТЫРЫШЫНДА

## Елга йомгак ясап

**9нчы февральдә район мәдәният йортында дүртенче чакырылыш муниципаль район Советының алтынчы утырышы үтте. Утырышта, депутатлардан тыш, республиканың Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт комитеты рәисе Х. М. Мәхмүдов, БР Башлыгының урындагы үзидарә органнары белән эшләү буенча Идарәлеге бүлегенең баш советнигы В.А. Жебровский, район Советы һәм хакимиятенең җаваплы вазыйфалы хезмәткәрләре, киңкүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, сугыш һәм хезмәт ветераннары, оешма, предприятие, учреждениеләр җитәкчеләре, мәктәп һәм мәдәният йортлары директорлары, балалар бакчалары мөдирләре, эшкуарлар, хокук саклау органнары җитәкчеләре, полициянең төбәк вәкилләре, сәламәтлек саклау хезмәткәрләре, сәяси партияләр, җәмәгать оешмалары вәкилләре һәм дин әһелләре катнашты.**



Совет утырышында муниципаль район хакимияте башлыгы **Борис Нурисламов** “Муниципаль Борай районының 2016 елдагы эшчәнлеге һәм 2017 елга социаль-икътисади һәм мәдәни үсеш перспективалары хакында” отчет докладь белән чыгыш ясады.

Район җитәкчесе үзенең чыгышында узган елда районда барлык тармакларда башкарылган эшләргә ныклы анализ ясап, ирешелгән уңышларны һәм булган җитешсезлекләрне билгеләде, киләчәккә бурычлар куйды.

“Муниципаль Борай район Советының 2016 елдагы эшчәнлеге турында” Совет рәисе **Рамил Вяльшинның** отчеты тыңланды. (Докладлар гәзитнең киләсе саннарында басылачак).

Докладлар буенча фикер алышуда катнашып, Совет депутаты, район хакимиятенең мәдәният бүлеге муниципаль казна учреждениесе начальнигы **Илгиз Харисов**, шулай ук Совет депутаты, район хакимиятенең мәгариф бүлеге муниципаль казна учреждениесе начальнигы **Фәрит Хуҗин**, Тазлар авыл Советы авыл биләмәсе башлыгы **Илүс Даутов**, “Аграр” крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы **Әхләф Зарипов** чыгыш ясадылар һәм докладларны тулыландырдылар.

Республика Башлыгы һәм Хөкүмәтенең рәсми вәкиле, Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт комитеты рәисе **Халит Мәхмүдов** үзенең чыгышында район Советы һәм хакимиятенең 2016 елда башкарган эшләренә уңай бәя бирде. Борай районының башка районнар арасында тотанаклы лаеклы урын алып торуын, узган елда күп кенә күрсәткечләрнең 2015 елга караганда югарырак булуын билгеләп һәм кайбер мәсьәләләр, бигрәк тә демографик хәлне яхшырту буенча тәкъдимнәрен, киңәшләрен әйтеп, 2017 елда район алдында торган бурычларны тормышка ашыруда уңышлар теләде, утырышта катнашучыларның бик актуаль һәм урынлы күтәрелгән сорауларына җавап бирде.

## Киләчәккә карап, үткәннәрне барлап

**Муниципаль Борай районы башкортларының XI Корылтаен ачу тантанасы башкорт халкының милли үзенчәлеген чагылдырган халык биюләре, җырлары, милли уен коралларыннан агылган көйләре белән ачылды. 7нче февральдә узган бу чарага 150дән артык кеше – район корылтаеның башкарма комитеты әгъзалары, район мәктәпләренең башкорт теле һәм әдәбияте укытучылары, китапханәчеләр, мәдәният хезмәткәрләре, оешма-предприятие җитәкчеләре һәм, гомумән, милли мәсьәләләргә кагылышы булганнар чакырылган иде.**

Корылтайга җыелучыларны башлап район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Хаматдинов сәламләде. Ул үз чыгышында районда милли тәрбия бирү җәһәтеннән барган эшләр турында бәян итте. Телләр турындагы законнарның тормышка ашырылуы, туган телләрне саклап калу һәрберебезнең бурчы булуы хакында сөйләде. Артабан сүз район башкортлары Корылтаеның башкарма комитеты рәисе И.Харисовка бирелде. Ул IV Бөтендөнья башкортлары Корылтае мәсьәләләренең районда тормышка ашырылу буенча отчет тотты. Район Корылтае башкарма комитетының җаваплы секретаре, 2015 елда оешкан “Ак инәйләр” җәмәгать оешмасы җитәкчесе Р.Солтанова, башкорт теле укытучылары М.Азнабаев, З.Ягафәрова, китапханәче Ф.Газизова, “Гүзәл” балалар үстерү үзәге педагогы З.Баһаутдиноваларның да докладлары башкарма комитет рәисе чыгышының дәвамы булып, мәгариф, мәдәният учреждениеләрендә, һәм гомумән районда барган башкорт телен һәм мәдәниятен үстерү, саклап калу җәһәтеннән башкарылган эшләргә байкау ясалды. Бөтендөнья башкортлары Корылтаеның Бөре районара җәмәгать оешмасы җитәкчесе, БДУның Бөре филиалы педагогы В.Ганиев – әлеге җыенның мәртәбәле кунагы, Борай Корылтае эшчәнлеген яхшы бәһалап, киләчәктә тагын да нәтиҗәлерәк эшләргә чакырды. Корылтайларның төп бурычы туган телне, мәдәниятне саклап калуга ярдәм итү икәнлеген искә төшерде. Башкортстанда яшәгән кеше телне белмәсә дә, аны аңларга, халыкның тарихын, мәдәниятен белергә тиеш. Бигрәк тә яшьләр арасында эшне активлаштырырга кирәк, диде ул. Яшьләрне җирдән файдаланырга, эшкуарлыкка өйрәтергә кирәк, үз җиребезгә үзебез хуҗа булырга тиешбез, кире очракта аңа хуҗалар тиз табылыр, дигән фикерне дә җиткерде.

Җыен ахырында Корылтайның яңа составы расланды, резолюция кабул ителде, башкарма комитеты рәисе итеп яңадан И.Харисов сайланды.

• АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА

## Махсус урын булдырылды

Борын-борыннан авыл халкы сугымлыкка симертелгән малын йорт ихатасында чалып эшкәртте. Калдыкларын җиргә күмде, чүплеккә ташлаган очраклар да юк түгел. Беренче карашка гади тоелган эшнең күңелсез тәмамлануы, ягъни ветеринария-санитария кагыйдәләре тиешенчә үтәлмәү сәбәпле, тирә-якта мал авырулары таралу, аннары кешеләргә йогу ихтималы зур иде. Менә шуларны булдырмау, эшне билгеле тәртипкә салып башкару максатыннан республика Хөкүмәте районнарда махсус мал чалу, ит эшкәртү, калдыкларын ташлау өчен үләт базлары төзү бурычы куйды. Хәзер һәр авыл биләмәсендә мөмкин кадәр уңайлырак урында һәм шул ук вакытта тиешле ераклыкта мондый базлар төзелде. Ә менә тулысынча ветеринария-санитария таләпләренә җавап бирүче, зур төзелеш чыгымнары кирәкле мал чалу урынын тиз арада булдыру, әлбәттә, җиңел түгел иде. Шулай да кыюлар табылды. Байтак еллар мал, кошкорт асрап дөнья көткән ирлехатынлы Фируза белән Илшат Хәлиловлар бу эшне йөкләп алды.

Хәлиловлар, трактор гаражын үз көчләре белән капиталь ремонтлап, мал чалу һәм итен эшкәртү цехын булдырды. Биредә барлык ветеринария-санитария таләпләре тиешле нормаларга туры килә. Анда кое казылып, су кертелде, краннан суык һәм җылы су агып тора, юынтык сулар, мал каны канализациягә агып төшә. Итне вакытлыча саклау өчен, бигрәк тә җәйге айларда, суыткыч урнаштырылган. Итне механизмнар ярдәмендә күтәреп элү җайланмасы да бар.

Мал чалучылар Зөлфәт Фәттахов, абыйлы-энеле Фәнүр белән Салават Садертдиновлар үз хезмәтләрен шәригать кануннарына яраклы башкара. Малның тиресе һәм эчке-тышкы органнары хуҗасына бирелә. Ит эшкәртү, билгеле, түләүле. Ул 1500 сумга төшә. Күптән түгел көтеп алынган юл мәсьәләсе дә хәл ителде, хәзер авылга асфальттан гына барасы.

–Китерергә транспорты булмаган кешеләрнең малын барып алырга мөмкинлек бар. Малны чалып, эшкәртеп, итен һәм башкасын илтеп бирергә дә була. Авылларда өлкән яшьтәгеләр дә мал-туар асрый, ләкин эшкәртү проблемасы авырлык тудыра. Мондый кешеләр безнең хезмәтне хуплый. Шулай ук күмәк хуҗалыклардан килүчеләр рәхим итсен. Киләсе җәйдә фермага кергәндәге чокырга су торбасы салып юлын берникадәр күтәрергә иде, – дип, киләчәккә планнары белән уртаклаша фермер хуҗалыгы башлыгы Илшат Хәлилов. Алар районда һәм Уфада оештырылган ярминкәләрдә актив катнашып үз продукцияләрен – кош һәм мал итен сата.

**Р. ФӘТХИНУРОВ.**



**Мал чалып итен эшкәртүче Зөлфәт Фәттахов белән Салават Садертдинов.**

## Сертификатлар – бүләккә

**“Океан” йөзү бассейны** борайлыларны якынлашып килүче бәйрәмнәр белән котлый һәм якыннарыгызга бүләк итү өчен сертификатлар тәкъдим итә. Аларның хакы, хезмәтләр төрлелегенә карап, 300дән 1000 сумга кадәр. Бәйрәмнәр уңаеннан якыннарыгызга сәламәтлекләрен ныгыту мөмкинлеге бүләк итегез. Сертификатларны бассейн кассасында алырга була. Реклама

## Китап бәйрәменә килегез

**14 февральдә** район балалар модель китапханәсендә “Сөю белән китап бүләк итегез” дип аталган чара үтә. **12.00 сәгатьтә** башлана. Рәхим итегез!

**26 февральдә** якташыбыз, танылган җырчы, Татарстанның халык артисты **Хәмдүнә Тимергалиева** район мәдәният йортында чыгыш ясый. Концертның кунаклары: **Илһам Шәриф, Иркә, Винарис Ильегет** һ.б. Җырлы-моңлы, чагу тамашадан читтә калмагыз. Башлана **19 сәгатьтә.**

Реклама

# Яңа кагыйдәләр буенча

*Законнардагы яңалыклар яшәешкә нинди үзгәрешләр кертә?*

**Быел көченә кергән мөһим законнарга күзәтү ясауны дәвам итәбез. Бу юлы хосусыйлаштыру, парк, җир участоклары, күчемсез милекне теркәү һәм газ җиһазлары өлкәсендә законнардагы үзгәрешләргә тукталачакбыз.**

### Торакны хосусыйлаштыру

«Русия Федерациясендә торак фондын хосусыйлаштыру турында» федераль закон 1991 елда ук кабул ителде. Шул чордан алып Башкортстанда 572 меңнән артык торак фонды объекты хосусыйлаштырылды. Республиканың Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгыннан белдерүләренчә, фатирын хосусыйлаштырырга теләүчеләрнең күпчелеге 25 ел эчендә бу мөмкинлектән файдаланган, шуңа да сделкалар саны кимүгә таба бара.

Закондагы соңгы төзәтмәләргә ярашлы, түләүсез хосусыйлаштыру вакыты 2017 елның 1 мартында чыга. Бу социаль наймдагы торакны хосусыйлаштыру өчен җитәрлек вакыт. Моның өчен 1 мартка кадәр вәкаләтле органга (Уфада — Җир һәм милек мөнәсәбәтләре идарәсе, шәһәр һәм районнарда — муниципалитетлар хакимиятләре) гариза бирергә кирәк.

Ятим балалар, авария хәлендәге торакта, Кырым һәм Севастопольдә яшәүчеләр өчен хосусыйлаштыру вакыты 2020 елның 1 гыйнварына кадәр озайтылды, дип яза «Российская газета».

Башка очракларда торакны дәүләттән сатып алырга гына мөмкин булачак. Әмма әлегә бу механизм эшләнеп бетмәгән.

### Җир участоклары

Җир участокларын бирү кагыйдәләре дә үзгәрде. Законга төзәтмәләрне Дәүләт Җыелышы-Корылтай депутатлары кертте («Башкортстан Республикасында җир мөнәсәбәтләрен көйләү турында» Башкортстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 5-539/з санлы закон).

Хәзер җир участоклары биргәндә льготалы категориягә караган гаилә яшәгән торак бинасының мәйданы исәпкә алыначак. Гаиләнең бер әгъзасына туры килүче гомум мәйдан урындагы үзидарә органнары билгеләгән нормадан кимрәк булырга тиеш. Уфада, мәсәлән, бу норма бер кешегә торакның гомум мәйданының 12 квадрат метрын тәшкил итә.

Күпбалалы һәм инвалид бала тәрбияләгән гаиләләргә, аларның дәүләт ярдәменнән башка үзаллы алган яисә сатып алган участоклары булса да, яңа җир участогы бирүдән баш тарта алмаячаклар. Башка категория гражданнарга да, милекләрендә күләме 8 сутыйдан арткан участок яисә мәйданы нормадан арткан фатир булганда гына, җир участогы бирмәскә мөмкиннәр. Элек исә теләсә нинди зурлыктагы җир участогы булу да яңа җир участогы бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора иде.

Гаилә торак шартларын яхшыртуга (мәсәлән, «Яшь гаилә» программасы буенча) бюджеттан акча алган очракта гына (ана капиталыннан башка), түләүсез җир участогы бирелмәячәк.

Гариза бирүче милеккә түләүсез җир участогы бүленү турында белдерү кәгазе алганнан соң 30 көн эчендә үзенең ризалыгын бирергә тиеш. Әгәр дә ризалык алынмаса, әлеге участок чиратта торучы киләсе кешегә тәкъдим ителә. Шул




> **Гражданнар газ җиһазларын техник хезмәтләндерүнең кирәкле һәм кичектергесез чара булуын аңласын иде**

ук вакытта ризалыгы алынмаган кеше дә исәптән төшерелми.

Белдерү кәгазьләре почта билгесе белән өч тапкыр кире әйләнеп кайткан очракта гына, граждан исәптән төшерелә. Бу очракта да, әгәр кәгазьләр вәкаләтле орган тарафыннан җир комиссиясенең җир участокларын бүлү турында өч карары нигезендә җибәрелгән булса гына. Шул ук вакытта, исәптән төшерелү гражданны вәкаләтле орган — муниципалитет хакимиятенә әлеге мәсьәлә буенча яңа мөрәҗәгать итү хокукыннан мәхрүм итми.

Чират турында мәгълүмат вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла һәм кварталга бер тапкыр яңартыла.

Закондагы үзгәрешләр көченә кергәнче (ягъни 2017 елга кадәр) исәпкә басучы гражданнар үзгәрешләр кертелгәнче гамәлдә булган шартларда җир участоклары алу хокукыннан файдалана.

— Максатыбыз — ярдәмне аңа мохтаҗ булганнарга күрсәтү, — ди **Дәүләт Җыелышы-Корылтай Рәисе Константин Толкачев**. — Күпбалалы гаиләләрнең матди хәле төрлечә. Шуннан чыгып, һәр гаиләгә аерым килү, ярдәмне, чыннан да, аңарга мохтаҗларга күрсәтү зарур.

### Күчемсез милекне теркәү

1 гыйнвардан күчемсез милекне экстерриториаль рәвештә дә теркәргә мөмкин. Ягъни, хәзер документлар кабул итүче офиска, күчемсез милекнең кайда урнашуына карамастан, хокукны теркәү мәсьәләсе белән мөрәҗәгать итәргә була («Күчемсез милеккә дәүләт теркәве үткәрү турында» 218 санлы Федераль Закон). Мәсәлән, хәзер сез Мәскәүдәге фатирны Башкортстанда милеккә терки аласыз. Бу максатта Русиянең һәр төбәгендә Росреестрның аерым офислары ачылган. Башкортстан территориясендә күчемсез милеккә хокукны экстерриториаль принцип буенча теркәү өчен документларны Уфада Росреестрның СССРның 50 еллыгы, 30/5 йорт (2 санлы зал) адресы буенча урнашкан бүлекчәсендә бирергә мөмкин.

### Машина кую урыны да — хосусый милекме?

Быел «Русия Федерациясе Гражданнар кодексының беренче өлешенә һәм Русия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 315 санлы Федераль Закон көченә керде. Аңа ярашлы, хәзер машина кую урынын сатып алып, сатып, арендага биреп, мирас итеп, залогка калдырып булачак. Бу шулай ук йорт ихатасындагы машина кую урынын да шәхси милеккә әйләндереп булачак, дигәнне аңлатамы?

Төздә машина кую урыны дигән төшенчәгә ачыклык кертергә кирәк. «Российская газета» аңлатуынча, бинаның яисә башка корылманың транспорт чарасын кую һәм саклау өчен тәгаенләнгән өлеше генә машина кую урыны булып тора. Ул стена яисә башка төр конструкцияләр белән киртәләнгән алынырга, яисә бөтенләй киртәләнмәгән гадәти мәйданчыкны хасил итәргә мөмкин. Әмма нинди генә очракта да аның чикләре турында мәгълүмат Росреестрда теркәлгән булырга тиеш.

— Закон биналардан, корылмалардан читтәге җир участокларында урнашкан машина кую урыннарына кагылмый. Андый объектлар үзаллы була алмый, — ди «Клифф» юридик фирмасының күчемсез милек практикасы өлкән юристы Анжела Полторак.

Ягъни шул рәвешле, ихатадагы гадәттә автомобилегезне куя торган урынга үз хокукларыгызны белдерә алмаячаксыз.

### ОДН — яңача

Моннан алдагы күзәтүдә без гомумйорт ихтыяҗлары өчен түләү исәпләүнең яңа тәртибе турында кыскача сөйләгән идек инде. Газет укучыларның күпсанлы сораулары бәйле бу темага янә әйләнеп кайтабыз.

Исегезгә төшерәбез: ОДН электр энергиясе, кайнар һәм салкын су өчен исәпләнә. Һәм милекчеләр элеккечә фатир эчендә коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен дә, гомумйорт ихтыяҗларына тотылганы өчен дә түләргә тиеш. Элек гомумйорт ихтыяҗлары чыгымнарын коммуналь хезмәтләр өчен түләү графасына кертсәләр, хәзер алар торак бинаны тоту өчен түләү графасына кертелә. Моннан тыш, яңа елдан ОДНга түләү нормативлар белән дә чикләнә.

— Кайбер йортларда без ОДН өчен исәпләнгән түләүләрдә күләме бик зур булуын күреп, шаккаттык, — ди **республиканың Торак һәм төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт комитеты рәисе Илдар Шәфыйков**. — Хәзер мондый очраклар үткәндә калачак. Нормативтан тыш исәпләнгән акчаны идарә итүче компаниянең үзенә түләргә туры киләчәк.

Бу яңалык гражданнарның хокукларын яклауга юнәлтелгән. Идарә итүче компанияләр энергияне сакчыл тотыну һәм ресурсларны экономияләү юнәлешендә активрак эш алып барачак.

Әлегә былтыр билгеләнгән нормативлар кулланылачак — алар белән tariff.bashkortostan.ru сайтының «Документлар» бүлегендә (республиканың Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 29 сентябрендәге 120 санлы карары һәм 2016 елның 25 июлендәге 81 санлы карары) танышырга мөмкин.

Шушы елның 1 июленә кадәр нормативлар яңадан каралачак, дип көтелә.

### Сак булыгыз — газ!

Газдан файдалану кагыйдәләре дә катгыйланды. Русиянең Административ хокук бозулар турында кодексына (аның 9.23. маддәсенә: «Йорт һәм фатир эчендәге газ җиһазларын хәвефсез файдалануны һәм тотуны тәэмин итү кагыйдәләрен бозу») үзгәрешләр кертелде. Хәзер эшкә салкын караган газ хезмәткәрләре генә түгел, ваемсыз йорт һәм фатир хуҗалары да штрафка тарттырылачак.

Республиканың Торак һәм төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт комитетыннан белдерүләренчә:

*— йортларда һәм фатирларда газ җиһазларын хезмәтләндерү буенча эшләрне башкару (хезмәт күрсәтү) сыйфатына (вакытына, хезмәтләндерү ешлыгына) таләпләрне бозган өчен;*

*— техник хезмәтләндерүгә килешү төзүдән баш тарткан өчен;*

*— йорт һәм фатир эчендәге газ җиһазларын техник хезмәтләндерү буенча эшләрне башкаручы махсуслаштырылган оешма вәкилен кертмәгән өчен;*

*— йорт һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазлары составына керүче корылманы алыштырудан баш тарткан өчен*

***штрафлар каралган:***

*— гражданнарга — бер мең сумнан ике мең сумга кадәр;*

*— вазыйфалы кешеләргә — биш мең сумнан егерме мең сумга кадәр;*

*— юридик берәмлекләргә — кырык мең сумнан йөз мең сумга кадәр.*

— Гражданнар газ җиһазларын техник хезмәтләндерүнең кирәкле һәм кичектергесез чара булуын аңласын иде, — ди республиканың Торак һәм төзелеш күзәтчелеге буенча дәүләт комитеты рәисе Илдар Шәфыйков. — Идарәче оешмаларга киңкатлам халык арасында аңлату эшләре алып бару өчен Газ җиһазларын көнкүрештә дөрес куллану буенча памяткалар җибәрелде. Гражданнарны вентиляция каналларында һәм төтен юлларында тарту көче булмаганда, газ җиһазлары дөрес эшләмәгәндә (шартлау тавышы, газ исе булганда), газдан файдалануны туктатып, тиз арада махсуслаштырылган газ хезмәтләренә мөрәҗәгать итәргә чакырам. Төзекләндерү эшләрен башкару өчен газ хезмәте хезмәткәрләрен бинага кертү зарур, бу авария хәлләренә юл куймау һәм шартлауларны булдырмау өчен кирәк.

Приглашаются водители с ЛИЧНЫМ АВТО для работы ВАХТОЙ в Уфе в Яндекс.Такси.
Проживание, питание. З/п – от 25 000 руб.
Тел.: 8-800-301-9-301 (бесплатно)
ОГРН 1150280038105
РЕКЛАМА

Материалларны «Башкортстан Республикасы» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе редакциясе әзерләде.

• АВЫЛ СОВЕТЛАРЫНДА

# Киләчәккә җитди бурычлар куелды

**Узган җомгада Борай авыл Советы депутатлары утырышында еллык эшчәнлеккә отчет ясалып, киләчәккә әһәмиятле бурычлар куелды.**

Борай авыл Советы биләмәсенә караган Бикҗән, Дүсмәт, Шабай һәм Шүнәк авылларында бүгенге көндә 11 мең 541 кеше яши. Аларның 40 проценты – пенсионер, бу 4 мең 600 кеше, балалар – 2 мең 400, хезмәт яшендәгеләр – 5 мең 500 кеше. 2 мең 300 кеше биләмә территориясендә эшләсә, 2 мең 200е районнан читтә хезмәт сала. 2008 елдан башлап, туучылар саны үлүчеләрдән өстен.

"97 урамнан бүгенге көнгә, гомум озынлыгы 120 километр тәшкил иткән 139 урам барлыкка килде. Соңгы 5-6 ел эчендә өч һәм аңардан күбрәк бала тәрбияләгән, инвалид бала караганнарга, яшь гаиләләргә, бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә барысы 860 җир участогы бүленде. Әлеге вакытта шушы сорау буенча мохтаҗлар саны – 407. "Иске Борай"дагы яшәп яткан җир участокларын бүлү һәм шунда балаларына яки сатарга өй төзү күренешләре ешайды. Аларны сатып алучылар магазиннар төзи, шунлыктан электр һәм газ куәтлелегенә көч килә,"– диде биләмә башлыгы Айрат Кәримов башкарылган эшләрне барлаганда. Ел агымында тотылган чыгымнарның төп өлеше авылларны төзекләндерүгә, урамнарны ремонтлау һәм яктыртуга, коммуналь хезмәтләр башкаруга юнәлтелгән. Авыл Советы халыкка көнкүрештә кирәкле хезмәтләр күрсәтүне "Жилищник", районның юл төзү һәм ремонтлау идарәлеге, муниципаль унитар "Электр челтәре" предприятиесе һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлектә эшлекле оештырган. Мәгълүм булуынча, "Авария хәлендәге тузган йортлар" программасы буенча Вострецово урамында күпфатирлы йорт төзү эше дәвам итә. Бикҗән авылына субсасымы башнясы кайтарылган. Дүсмәт авылы зираты территориясен төзекләндерү күз уңында тотыла. Юлларны кышкы-җәйге чорда тәртиптә тоту һәм башка көнкүреш оештыру эшләре яхшы темпта бара. Узган ел ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар өчен 7 торак бүленгән. Бөек Ватан сугышында катнашкан өч ветеранның тол хатынына торак алу өчен сертификат тапшырылган. Әйткәндәй, шунысы кызганыч, Борай авыл биләмәсендә Бөек Ватан сугышы ветераннарының исәннәре 8 генә калды.

Биләмәдәге хәлләр, вакыйгалар, булган проблемаларны хәл итү Советтагы 14 депутат катнашлыгында тормышка ашырыла. Кеше өчен уңайлы шартлар тудыру, лаеклы яшәешне тәэмин итү буенча авыл Советы депутатлары утырышында барысы да уртага салынып сөйләшелде. Депутатлар: Т. Гарифҗанов ("Жилищник"), Н. Хәмидуллин ("Электр челтәре"), Б. Ибраһимов (шәхси эшкуар) ел барышында башкарылган эшләр һәм киләчәккә планнары белән уртаклашты. Шулай ук авыл Советы депутатлары утырышына килгән сайлаучылар да үз фикерләрен әйтеп үттеләр: җәйге айларда малларның урамнарны пычратып, иясез йөрүе, бер кәҗә өчен дә хуҗасына административ штрафның 1 мең һәм унысы өчен дә шул хак кына булуы, ә салынган зыянның чагыштырмача зур булуы борчый. Бәлки, җәзаларны катгыйландырсаң, хуҗалар маллары өчен игътибарлырак булыр иде, дигән һәм башка сораулар уртага салып сөйләшелде.

Биләмә башлыгы А. Кәримовның ел йомгаклары буенча ясалган эзлекле докладын, муниципаль район хакимияте башлыгы урынбасары Р. Галләметдиновның тормыш шартларыбызның канәгатьләнерлек булуы һәм ел саен яхшыра барганлыгы турында сөйләве һәм 2017 ел – Экология елы булганлыгын, экологик эшләр тагын да ныграк җәелдереләчәге, тазалык һәм чисталык сагында районда шларыбызның шәхси үрнәге белән бердәм тотыну кирәклеге ассызыклады. Милек белән идарә итүнең район комитеты рәисе Р. Хәйруллина җир участокларының исәпкә куелуы, теркәлү үтеп, район бюджетына салым кертү – районда яшәү шартларын яхшыртуга нигез булганлыгын искә төшерде.

Халык үз ышанычын белдергән депутатларның тынгысызлыгын һәм җитеш тормышка илтүче тәкъдимнәрен ишетеп, сайлаучыларның ышанычын фәкать аклаrлар дигән ныклы уй туа.

**М. ӘХМӘТҖАНОВА.**

# Авыллар яңарыш юлында

**Яңа Тазлар авыл биләмәсе авыл Советы районда зурлардан исәпләнә. Ул җиде авылны берләштерә. Аның биләмәләре аша республика әһәмиятендәге олы юл үтү, ял итү урынына әйләнгән Аккош күленең янәшәдә булуы һәм, әлбәттә, аны ел әйләнәсендә чиста, төзек тоту, авыллардагы эчке тәртип, тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, кешеләрне эш урыннары белән тәэмин итүдә ярдәмләшү, чүплекләрне, урамнарны төзекләндерү һәм кичләрен яктырту, эчәр су мәсьәләсен хәл итү, шәхси ихаталарны һәм пай җирләрен, печәнлекләрне рәсмиләштерүне оештыру кебек һәм башка бихисап мәшәкатьләр санаулы гына кешеләр иңенә йөкләнгән. Авыл биләмәсе хакимияте аларны башкаруда авыл Советы депутатлары һәм урындагы күмәк һәм крестьян-фермер хуҗалыклары, шәхси предприятиеләр ярдәменә таяна. Биредә Яңа Тазларда "Кама", Яңа Кизгәндә "Шафиков", "Шәйхинуров", Чишмә-Борайда "Хәлилов" шәхси предприятиеләре уңышлы эшли. Үз эшләрен яңа ачучылар да бар. Алты авылда фельдшер-акушерлык пунктлары, клуб һәм китапханәләр халык мәнфәгатендә эшли. Бу төбәктә Яңа Тазлардагы урта мәктәп һәм аның ике филиалының укытучылар коллективы, балаларга тәпле белем бирү белән беррәттән, авыл тормышын ямьләүдә, төрле бәйрәм чараларында, җыелышларда актив катнаша.**

Шушы көннәрдә үткән еллык эшкә отчет доклады белән чыгышында авыл биләмәсе башлыгы Илүс Даутов депутатлар һәм авыл активы каршында 2016 елда башкарылган эшләрне барлады.

Былтыр бу төбәктәге авылларны төзекләндерү, анда яшәүчеләргә уңайлы тормыш-көнкүреш шартлары булдыруда зур мәшәкатьләр башкарылды. Шулардан Чишмә-Борай һәм Касияр авылларының халкы күп еллар дәвамында көтеп алган юллар салынды,Чишмә-Борайда сугыш һәм тыл ветераннарының батырлыгын мәңгеләштерү йөзеннән һәйкәл ачылды, клуб ихатасы ремонтланды, Иске Тазларда һәм башка урыннарда урамнар төзекләндерелде, коелар казылды, зәңгәр ягулык кертү һәм аңа шәхси йортларны тоташтыру бара, бу эш киләчәктә дә дәвам итәчәк. Урындагы халык башлангычларын яклау программасына кереп, хөкүмәт ярдәме һәм халыктан җыелган акча исәбенә Яңа Тазларда су башнясы урнаштырыла, урамнарны төзекләндерү буенча хәстәрлек күрелә. Районда бердәнбер мал чалу цехы да әлегә Чишмә -Борайда Илшат Хәлиловның шәхси предприятиесендә генә эшли. Саный китсәң, биредә шундый уңай мисаллар күп. Шул ук вакытта проблемалар да юк түгел. Җыелышта катнашып чыгыш ясаган муниципаль район хакимиятенең авыл хуҗалыгы бүлеге җитәкчесе Ялкын Гыймалтдинов басуларны маллардан таптатуга, эшкәртелмичә буш яткан җирләргә, шәхси ихаталарның һаман да дәүләт теркәве үтеп рәсмиләштерү тәгәлләнмәвенә борчылу белдерде.

Ул, киләчәктә бу төбәктә фермерлар эшчәнлеген арттыру кирәклеген, бөртекле һәм мал азыгы культураларына сорау зур булачагын ассызыклап, эшлекле тәкъдимнәрен әйтте. Җыелышта "Кама" хуҗалыгы рәисе Рәиф Галләмов, Яңа Тазлар мәктәбе директоры Лүзә Дугинова һәм башкалар чыгыш ясады.

**Р. ШӘЙМӨХӘМӘТОВ.**



# Компьютер ярдәмгә килә

Борай район электр челтәрендә көч салучы энергетиклар барлыгы 1200 чакрым озынлыгындагы электр линияләрен, авылlardагы алты урындагы подстанцияне һәм 339 трансформатор пунктын хезмәтләндерә. Аларны төзек эшләтү, өзекләнкләргә юл куймау максатында әлеге предприятиедә дүрт дистәдән артык энергетик, инженерлар, диспетчерлар көч сала. Биредә автомеханик Фидәрис Зәйнетдинов (рәсемдә) унөч берәмлек махсус техника эшчәнлеге өчен җаваплы. Урыннарда эш барышына контрольлек итүдә аңа компьютер ярдәмгә килә, һәр техника ГЛОНАСС системасына тоташтырылган һәм аларның кайсы авылда булулары экранда ачык күренә. Бу төпкелдәге авылларда, элемтә булмаган урында техника сафтан чыккан очракта уңайлы, тиз хәбәр итеп, техник ярдәм сорарга була.

**Р. ШАМАТОВ.**

• ПРОКУРАТУРА ХӘБӘР ИТӘ

# Хезмәт мөнәсәбәтләре законлы булсын

**Иске Карагыш авылы кешесенең мөрәҗәгате буенча район прокуратурасы әлеге авыл фермерының хезмәт законнарын үтәвен тикшерде.**

Крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе дүрт гражданны төрле эшләрдә эшләүгә җәлеп иткән, ләкин алар белән хезмәт килешүе төземәгән һәм эш хакын "конвертта" биргән. Мәҗбүри медицина һәм страхование фондларына, шулай ук пенсия фондына түләүләр бармаган.

Прокурор хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерүгә ирешә, эшкуарга 5 мең сум штраф салынды.

**Б.ГАЛИӘКБӘРОВ,**
**район прокуроры урынбасары.**

• КӨНҮЗӘК

# Юлсызлык ике кулсыз калдыра

Кышның үз авырлыклары: бураны, ерып чыкмаслык көртләре… Авыл кешесен юлсызлык, хыялларны, өметләрне кискән кебек, ике кулсыз калдыра. Русиянең бәласе элек-электән юлларның булмавы инде. Ә менә кышларын көрттән ни җәяү йөреп булмый, ни машина белән. Ярый ла авылында колхоз, фермер хуҗалыклары булса. Атнага бер булса да, безнең авылның да урамнары кардан тазартыла. Кайсы чакта киң итеп, кайсы чакта тар гына, машиналар тыкрык башларында бер-берсенә юл бирер өчен көтеп, үз чиратын көтеп торалар. Мәктәп белән магазинга бару да авырга төшә. Мәктәпкә баручы укучылар, балалар бакчасына бәләкәчләрне илтүче әти-әниләр "сират күпере"н үткәндәй, җәфаланып бетәләр. Магазинга икмәк китергән машина да бата-чума керә һәм чыга. Ә юл эттерүче КамАЗ "остановка"га тиклем килә дә, кирегә китә. Мәктәптән олы юлга чыкканчы бер километр гына бар, ә шул ара тотынылмаган килеш кала бирә. Ярый әле авылыбыз уңганнары Салават Гайсин, Илшат Гайсин, Филгать Нәбиуллин, Риф Нәбиуллин, Азат Нургаянов, Рөстәм Зиннуров юлларны сирәк булса да, карап, кардан арчалыйлар. Алар үз техникасы белән тар гына итеп ачалар, бар урамнарга да өлгерәлмиләр, көчләреннән дә килмидер инде. Шушы игелекле авылдашларыбызга зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.

**Р. ИСХАКОВА,**
**Силасау авылы.**

• "ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ - 2017"

# Һөнәри осталык бәйгеләрдә сынала




**Күптән инде традицион чарага әйләнгән "Ел укытучысы" бәйгесенең муниципаль этабы быел да гөрләп үтте. Укытучыларның тырышлык нәтиҗәсе, иҗади эзләнүләренең тирәнлеге нәкъ шушы конкурста ачык чагыла.**

Укытучының ихласлыгы, һөнәренә бирелгәнлеге, белем һәм тәрбия уртаклашу дәрәҗәсе өчен иң зур бүләк– укучыларының аңа карата ихтирамы һәм сөю. Бу изге вазыйфаны һәр мөгаллим үтә сабырлык белән күтәрә. Шундый бәйгеләрдә катнашырга вакыт һәм көч табып, эш тәҗрибәсен мәртәбәле жюрига да тәкъдим итәләр.

"Ел укытучысы-2017" конкурсы, гадәттәгечә, өч турда үтте. Эссе жанрында иҗат ителгән "Мин – укытучы" язмасында бәйгедә катнашучыларның фикер киңлегенә, акыл тирәнлегенә, фәлсәфи карашына, әдәби бәян итә белү осталыгына да аерым игътибар ителде.

Икенче тур – һөнәри белдыклылыкны бәяләү – ачык дәрес күрсәтү һәм класс сәгате үткәреп, балалар белән иркен әңгәмәләшү, уртак тел таба белүне бәһалаудан гыйбарәт иде.

Өченче тур – "Мастер-класс күрсәтү". Финалистларның үзләре сайлаган тема буенча белем бирү технологияләрен тамашачы алдында игътибарны ауларлык тәкъдим итүләрен килүчеләр йотлыгып карап утырды.

Республика конкурсының муниципаль этабында катнашкан район педагогларын район хакимияте башлыгы урынбасары Николай Хаматдинов ирешелгән уңышлары белән котлады һәм киләчәктә дә иҗади хезмәт юлы теләде. Районның "Ел укытучысы – 2017" җиңүчесе булып Светлана Шуварова (инлиз теле, гимназия) танылды. Икенче урынга – Алмаз Хәйдаров (математика, беренче санлы мәктәп), өченчегә Илнур Сафин (тарих, Ваныш мәктәбе) һәм Гөлнара Хәсниярова (инглиз теле, өченче санлы мәктәп) чыкты. Конкурс нәтиҗәләре буенча өч номинация җиңүчеләре: "Татар теле һәм әдәбияте ел укытучысы – 2017" – Римма Әхмәтҗанова (Зур Бадрак мәктәбе), "Башкорт теле һәм әдәбияте ел укытучысы – 2017" – Ләйсән Муллагалиева (гимназия), "Яшь укытучы – 2017" – Илнара Хатмуллина (башкорт теле, Яңа Тазлар мәктәбе). Һәр катнашучыга Мактау грамоталары һәм бүләкләр тапшырылды. Мәгариф профсоюзы райкомы рәисе Ралис Камилҗанов та, үз чиратында, бәйгедә катнашучыларны ихлас котлап, аларга бүләкләр өләште.

Бу бәйге укытучының һәр көн дәвам иткән көчергәнешле хезмәте, тынгысыз тормышының бер көнлек мисалы гына иде.

**И. СӨЛӘЙМАНОВА**

# Өйрәнчекләрнең уңышы — осталарының тырышлыгы

**Балалар бакчасындагы музыка җитәкчесенең тынгысыз хезмәтен бертуктаусыз аккан чишмә белән чагыштырыр идем. Һәрвакыт хәрәкәттә, кечкенәләрне җыр-моң даирәсенә тәүләп алып керүче дә ул. Сабыйларның сәләтен үстереп, талантны күреп алырга тиешле кеше дә, балалар белән төрле конкурсларда катнашырга да нәкъ музыка җитәкчесе өлгерергә тиеш.**

Күптән түгел Уфада үткән конкурс-фестиваль кысаларында "Талант канатларында" исемле Халыкара проект булып узды. Бәйгене оештыручы– "Талантлар Планетасы" балалар һәм яшүсмерләр иҗатына ярдәм итү һәм үстерү Фонды оешмасы булды. Конкурсның төп максатлары һәм бурычлары: җыр һәм сәнгать иҗатын популярлаштыру, яшь талантларны барлау, саклау һәм үстерү, милли мәдәниятне нығыту иде. Анда "Гүзәл" балалар үзәге тәрбияләнүчесе Әнвәр Гарипов катнашты. Конгрес-Холлда үткән Гала-концертта чыгыш ясап, "Вокал" номинациясендә 2нче дәрәҗәле дипломга һәм Мактау грамотасына лаек булды ул. Әнвәрне бу бәйгегә педагогы Римма Әхмәтҗанова әзерләде. Римма Зөфәр кызының тәрбияләнүчесе "Сулпылар" телевизион тапшыруында катнашкан иде инде. "Борай талантлары" район конкурсында да Р. Әхмәтҗанова җитәкләгән "Вокал" түгәрәгенә йөргән Зөлфия Яппарова, Арина Сахратуллина, Әнвәр Гарипов, Әнвәр Гыйльметдинов, Анжелика Шәмсиярова, Азалия Вәсбиева, Руслан Хәмитов, Диана Ахунова, Елизавета Красильникова, Азалия Вәлиева уңышлы чыгыш ясады.



**И. ӘМИРОВА,**
**өлкән тәрбияче.**

# Бала һәм компьютер



**Соңгы елларда компьютер тормышыбызның бөтен өлкәләренә дә үтеп керде. Укытучы һөнәре дә эшчәнлегендә компьютер технологияләреннән файдалануны таләп итә. Мәгълүмат технологияләренең зур тизлек белән үсүе яшь буыннан белемле, иҗади фикер йөртүгә сәләтле булуны сорый. Бүгенге җәмгыять тыгыз мәгълүмат челтәре белән уратып алынган. Башлангыч сыйныфлар укытучысы буларак, дәресләрне кызыклы, нәтиҗәле, файдалы итүдә уку-укытуның сыйфатын яхшыртуда мәгълүмати технологияләрдән, аерым алганда Microsoft Word, Microsoft Power Point программалары, электрон почта, интернет челтәрләреннән файдалануның мөмкинлекләре зур дип саныйм.**

Безнең мәктәптә зур мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар, заманча җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшемдә кулланырга тырышам. Дәресләр өчен презентацияләр ясау укучыларда зур кызыксыну уята. Аларны яңа теманы аңлатканда, материалны ныгытканда, язучыларның тормыш юллары белән таныштырганда, класстан тыш чараларда кулланам.

Башлангыч сыйныфларда ук бала компьютер белән эш итәргә өйрәнә. Укучылар интернет челтәре аша кирәкле мәгълүматны табарга һәм системага салырга, презентацияләр төзергә өйрәнә, интернет аша төрле дистанцион конкурсларда катнаша, электрон почта белән эш итә.

Ләкин компьютер белән эш иткәндә санитария кагыйдәләрен һәм нормаларын истә тотырга кирәк. Аларны тәгәл үтәмәгәндә, сәламәтлеккә тискәре йогынтысы булуы мөмкин.

Бала компьютер алдында күпме утырырга тиеш соң? 2-3 яшьлекләр–15; 3-4–25, 5-6–35, 7-8–40 минут дип исәпләнә. Әлеге шөгыльне саф һавада булу, физик күнегү, хәрәкәтле уеннар белән чиратлаштыру шарт. Мониторда кояш нурлары, электр уты чагылышы булмаска тиеш. Мебельне дөрес сайлау да мөһим роль уйный. Өстәл, урындык һәм башка кирәк-яраклар балалар өчен җайлаштырылган булырга тиеш. Урындыклар тәгәрмәчле, аркасы көйләнә һәм урындык әйләнә торган булса яхшырак. Бу очракта бала үзенең позасын үзгәртә ала. Алар бик теләп мондый урындыкларда әйләнгәләп утыралар, димәк, күкрәк читлеге дә, умыртка баганасы да ял итеп ала. Мондый урындыкларда биеклекне һәр балага туры килерлек итеп көйләп була, ә бу, үз чиратында, талчыгуны киметә. Клавиатура яраклаштырылган тактаны булырга тиеш. Ул тактаны кирәк чакта тартып чыгарып, эш беткәч кире кертеп куярга мөмкин. Ә эш шунда ки, рәсем ясаганда, мышка белән эшләгәндә яки уйнаганда баланың өстәле биек булырга тиеш. Бу такта әйтелгән кагыйдәләрне үтәргә булыша, чөнки бала күп вакыт үзенең позасын үзгәртергә мәҗбүр була. Клавиатура стандарт биеклектән 7-10 см түбәнрәк урнашырга тиеш.

Компьютердан һәм интернеттан башка шәхеснең гармонияле үсеше була алмый. Әмма компьютер артында бик озак утыру да организмга файдага түгел. Әгәр ата-аналар башта ук түбәндәге киңәшләрне истә тотса, балалары компьютер уеннарына бәйле булмас:

-балага бүләк итеп компьютер сатып алмагыз, ул гаилә милке булып исәпләнсен;

-аның бүлмәсенә компьютер куймагыз;

- дисплей артында озак утыруның сәламәтлек өчен куркыныч булуын аңлатыгыз;

-балагыз белән күбрәк бергә булыгыз, табигатькә чыгыгыз;

-буш вакытында ул файдалы һәм кызыклы эш белән шөгыльләнсен;

-баланың компьютер алдында ашап утыруына чик куегыз, югыйсә ул аның начар гадәтенә әйләнәчәк.

Беркемгә дә сер түгел: бүгенге көндә балаларның күпчелек өлеше буш вакытларын компьютер артында уздыра. Әйдәгез, аларның бу мавыгуларына игътибарлырак булып, компьютерда уйнау вакытын чикләп, балаларның сәламәт, белемле һәм тәрбияле булып үсүләренә ирешик.

**Л.КӘРИМОВА,**
**Борай өченче санлы мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы.**

# Удмурт телендә иң яхшы әсәргә конкурс

2017 елда "Удмурт телендә иң яхшы әсәр" әдәби конкурсы игълан ителүе турында Удмурт Республикасының Матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат агентлыгы хәбәр итте. Анда удмурт телендә иҗат итүчеләр катнаша ала. Кайсы төбәктә яисә илдә яшәве мөһим түгел. Конкурсны регионның Матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат агентлыгы һәм "Кенеш" журналы редакциясе оештыра. Әсәрләр алты номинациядә билгеләнәчәк. Иҗади эшләрне агымдагы елның 15 февраленнән 15 ноябренә кадәр журнал редакциясенә (Ижау шәһәре, Пастухов ур., 13) китерергә яисә kenesh-udm@yandex.ru электрон адресына салырга кирәк. Конкурска йомгак 2018 елның гыйнварында ясала.

• НИЧЕК ЯШИСЕҢ, ВЕТЕРАН?

# Өлкәннәргә хөрмәт белән

**Районда барлыгы 8801 пенсионер бар. Әлбәттә, аларның байтагы, көтеп алынган лаеклы ялына сөенеп, йорттагы эше белән мәшгуль, бер ишесе исә оныкларын тәрбияләп куана. Әмма яраткан эшеннән аерылмаган 917 пенсионер үзенең бай хезмәт тәҗрибәсен яшьләргә өләшә әле.**

Район буенча барлыгы 4748 пенсионер хезмәт ветераны исемен йөртә, шуларның 1965е төрле Хөкүмәт бүләкләренә лаек булган. 1049 тыл ветераны бар. Район ветераннар советы нәкъ менә шушы кешеләр мәнфәгате белән яши. Авылларда барлыгы 62 башлангыч ветераннар советлары эшли. Аларга абруйлы кешеләр җитәкчелек итә. Җәмәгать башлангычында гына эшләсәләр дә, алар пенсионерларның яшәве, көнкүреше белән кызыксынып тора. Әлбәттә, советларның активлыгы төрле урында төрлечә. Бер урында, мәсәлән, совет рәисе һәр пенсионерның хәлен белеп, мохтаҗлар хакында югары оешмаларга хәбәр итеп, чарасын күрү артыннан йөрсә, кайберәүләре рәис булып сайланганнан соң бер әби яисә бабай янына бармаганнар да бар әле.

Ветераннар үз дөньяларына бикләнеп ятмасын өчен нинди чаралар күрелә соң? Районда өченче буын университеты эшләп килә. Аның өч юнәлеше бар, боларга 80ләп кеше йөри. Бигрәк тә компьютерга өйрәтү курслары актуаль, аларда 20 кеше белем ала. Болардан тыш, спорт, үзешчән сәнгать, кул эшләре белән дә шөгыльләнергә мөмкин. Дәресләрне алып баручыга түләү проблемасы юк, бары тик чара үткәрергә урын табарга, занятиеләргә пенсионерларны җәлеп итәргә генә кирәк.

Ветераннар арасында үзешчән сәнгатькә тартылучылар шактый. Район буенча 600ләп пенсионер концерт, театр жанры буенча түгәрәкләргә йөри. Алар катнашмаган бер сәхнә чыгышы да булганы юк. Фестивальләрдә өлкәннәр төп көчне тәшкил итәләр. Үткән елда тоташ пенсионерлар көче белән генә концерт оештырылып, ул зур уңыш яулады. Хор һәм җиде фольклор коллективлары уңышлы эшли. Талантлы пенсионерлар белән тырышып эшләгән мәдәният бүлегенә, район мәдәният йортына рәхмәтлебез.

2016 елда 14 пенсионер туристик экскурсиядә булды, 14 кеше санаторийларда үзенең сәламәтлеген ныгытты.

Спорт өлкәсендә ветераннар аеруча нәтиҗәле эшли. Бар ярышларда да алар призлы урыннарны яулый. Шахмат, волейболда күрсәткечләре бигрәк тә югары.

Шунысын да әйтергә кирәк, әлеге өлкәләрдә шөгыльләнергә теләүчеләр өчен ишекләр ачык. Мәсәлән, район ветераннар хорына ир-егетләр бик тә кирәк.

Үткән елда 22 сугыш ветераны яисә аларның тол хатыннары үзенең торак шартын яхшыртты, әле 12 кеше моңа чиратта тора, ягъни гариза язган. Бөек Ватан сугышы ветераннарына, аларның тол хатыннарына торак яхшырту федераль бюджеттан финанслана, шуңа гаризалар бары шул финанс бүленгәндә генә канәгатьләндерелә.

Ветераннар өйләрендә бикләнеп кенә ятмасыннар, хәрәкәттә булсын өчен төрле шартлар тудырыла. Мәсәлән, яңа төзелгән "Океан" бассейны пенсионерларны ярты хакка гына хезмәтләндерә, ягъни көндезге якта 50 сумга, кичке якта 65 сумга суда йөзә аласың. Мондый шартлар башка кайбер учреждениеләрдә дә бар. Чаңгы спортын яратучылар кышын рәхәтләнеп шөгыльләнә ала. Биредә инициатива белән энтузиазм пенсионерларның үзләреннән тора.

Ветераннарны медицина ягыннан хезмәтләндерү яхшыра. Әйтик, район поликлиникасында төштән соң кабул ителү, аңа телефон аша язылу мөмкинлеге – шуларның берничәсе.

Район ветераннар советына үткән ел 15 гариза керде. Алар буенча шактый эш башкарылды. Совет төрле партияләр, яшьләр оешмалары белән бергә эшли. Мәсәлән, 2016 елда "Бердәм Русия" партиясе белән берлектә "Ихлас" кибетенә изгелек әрҗәсе куелды. Аңарга халык салган продуктларны аеруча мохтаҗлык кичергән пенсионерларга таратып чыктык. Яшь гвардия белән бергә инвалид балаларга, янгынннан зыян күргәннәргә акча җыю оештырылды.

Районда 35 һәйкәл һәм обелиск ачылган. 26 туган якны өйрәнү һәм дан музейлары бар. Алар мәктәпләрдә һәм мәдәният йортларында урнашкан. Биредә сугыш һәм хезмәт ветераннары, сугышчы-интернационалистлар белән очрашулар үтә. Бөек Ватан сугышы ветераннары районда – 24, ә сугышчы-интернационалистлар исә 45 кеше.

Быел республикада һәм районда ветераннар советлары оешуга 30 ел тула. Юбилей елы ветераннар советларының актив эш чоры булырга тиеш. Ә бу өлкәдә эшлисе бик күп әле. Һәр пенсионер аларның барлыгын белергә, аның хәстәрен тоярга тиеш.

**Р. ЗИЯТДИНОВ,**
**район ветераннар советы рәисе урынбасары.**

# Күзәтчелек органнары хезмәткәрләре рейдлар үткәрде

Республика, район территориясендә көннәр салкын тору сәбәпле, гражданнар өйләрендә өстәмә җылыту приборлары куллана башлады, шул исәптән газ белән эшләтелә торганнарын да. Көнкүрештә кулланылган газны дөрес файдаланмаган очракта фаҗига булырга да мөмкин. Шундый күңелсез вакыйгаларны кисәтү максатында, Яңавыл районара күзәтчелек һәм профилактик эш алып бару бүлеге хезмәткәрләре өйдән-өйгә йөреп, профилактик кисәтү чарасы үткәрде.

Коткару ведомствосы хезмәткәрләре көнкүрештә кулланылган газның контрольдә тотканда гына ярдәмче икәнлеген искә төшерде. Күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен газны кулланганда хәвефсезлек кагыйдәләрен истә тотарга: газ хуҗалыгында инструктаж үтәргә; корылмалардан кулланганда башта бүлмәне форточканы ачып җилләтеп алырга; кинәт кенә газ килүе туктап калса, газ приборының краннарын ябарга; газ исе чыкканда газ приборларын сүндерергә, шырпы сызмаска, электр приборларын, утын кабызмаска, бүлмәне җилләтергә, 04 номерына яисә кесә телефоныннан 104 номерына шалтыратып, авария хезмәтен чакырырга кирәк. Көнкүрештә газдан файдаланганда газ приборларына кечкенә балаларны яисә алардан файдалану кагыйдәләрен белмәгән кешеләрне якын җибәрү, газ корылмасы урнаштырылган бүлмәдә йоклау, газ корылмасын үзаллы урнаштыру яисә ремонтлау тыела. Газ плитәсе янына тиз янучан әйберләр куярга, эшләп утырган килеш ташлап чыгып китәргә, аны өй җылыту өчен файдаланырга, өстендә кер яисә башка әйберләр киптерергә ярамый. Рейд барышында Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре менә шуларны гражданнарның исләренә төшерде һәм газдан файдаланганда җаваплы булырга чакырды.

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, 01 телефоны аша (кесә телефоннарыннан – 101 номеры) бердәм коткару хезмәтенә шалтыратыгыз.

**И.ФӘРВӘЗЕТДИНОВ,**
**өлкән инспектор.**

• САУЛЫК – ЗУР БАЙЛЫК

# Бер җылы сүз җитә

**11 февральдә билгеләнүче Бөтендөнья авырулар көне 1992 елның 13 маенда Папа Иоанн Павел II башлангычы белән булдырыла. Аның максаты – кешеләрнең игътибарын планетадагы авырулар проблемаларына җәлеп итү. Бу турыда Иоанн ишетеп кенә белми, 1991 елда табиблар аның үзенә "Паркинсон авыруы" дигән диагноз куя.**

Бу көнне бөтен дөньяда төрле авырулардан җәфа чигүчеләргә медицина учреждениеләре, социаль һәм сәяси оешмалар, аерым кешеләр тарафыннан теләктәшлек, сыйфатлы медицина хезмәте, шулай ук матди һәм рухи ярдәм күрсәтү зарурлыгын белдерү чаралары үтә.

Бар кешегә дә сәламәт булу бәхете тәтемәгән. Дөньяда авыру кешеләрнең артуына начар экология, эпидемия, икътисадый проблемалар сәбәп була. Болар барысы да яшәү сыйфатына, сәламәтлеккә һәм гомер озынлыгына тәэсир итә. Бу проблемалар ил хөкүмәте дәрәҗәсендә хәл итүне сорый, әмма һәрберебез чирле кешеләргә ярдәм күрсәтергә сәләтлебез.

Сәламәтлеге какшаган кеше өчен иң мөһиме – рухи ярдәм, игътибар. Безнең һәркайсыбыз, кайгыртучанлык күрсәтеп, авыру кешегә ярдәм итә ала. Җәфалану һәм сызлануларны ялгыз кеше аеруча авыр кичерә. Янында күңелен бушатыр кешесе булганда ул савыгуга таба бер адым үткән дип исәпләнә. Бу көннең төп максаты да авыруны савыктыру бит.

Монда сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны да читкә куярга ярамый. Чөнки чирне дәвалаганчы булдырмау яхшы. Сәламәт кешеләргә әлеге көнне саулыкларын ныгыту өстендә эшләргә була. Саулык – ул табигать тарафыннан кешегә бирелгән бәяләп бетергесез сәләт. Аны картлыгына ничек илтеп җиткерүе һәркемнең үзеннән тора. Актив тормыш рәвеше белән яшәгәндә, чыныгу, спорт белән шөгыльләнгәндә, начар гадәтләрне алга куймаганда, сәламәтлегегез ныгыячак. Авыру кеше хәлендә һәркем калырга мөмкин, шуның өчен аларга карата изге эшләр кылырга онытмыйк.

**М.ГОМӘРОВ,**
**мед. профилактика кабинеты табибы.**

# Туберкулез — мәкерле авыру

**Туберкулез – ул инфекцияле чир. Аны туберкулезның микробактерияләре, икенче төрле әйткәндә, Кох таякчыклары китереп чыгара. Туберкулез – бүгенге көндә бөтен кешелек дөньясына кагылышлы проблема. Аның белән дөньядагы халыкның өчтән бере авырый. Ел саен җирдәге гомум халык санының бер проценты зарарлана, 8,4 млн кеше туберкулез авыруы белән теркәлә һәм 2 миллионы үлә. Бу чир кешедән кешегә һава аша йога. Кызганычка каршы, эпидемик авыру кешене тышкы кыяфәтенә карап кына билгеләп булмый. Туберкулезны бер дә юкка гына, мәкерле авыру, димиләр. Аның белән авырыганлыкны үпкәдә ныклы үзгәрешләр башлангач кына белеп була.**



Чирне таратучылар – туберкулезның ачык формасы белән авыручылар. Сөйләшкән вакытта, төчкергәндә, ютәлләгәндә ул һавага төкерек белән бергә зур күләмдә бактерияләр бүлеп чыгара, алар төкерек кипкәннән соң да әллә күпме вакыт яшәүгә сәләтлелеген югалтмый, бигрәк тә кояш нурлары аз төшкән җирдә. Төрле предметларда бу таякчыклар алты-сигез айга кадәр яши. Ачык формадагы туберкулез белән чирләүче елына 10-15 кешегә чир йоктырырга мөмкин.

Авыру беренче чиратта үпкәне зарарлый. Чирне булдыручы бактерия эләгү әле туберкулез белән авыру дигән сүз түгел. Сәламәт кешенең иммунитеты аның организмны зарарлавына юл куймый. Статистика мәгълүматларыннан күренүенчә, организмына туберкулез таякчыгы кергән 100 кешенең бары тик бишесе генә шунда ук чирли.

Шуның өчен сәламәт тормыш рәвеше алып бару мөһим. Бигрәк тә нерв системасы сәламәт булырга тиеш. Сыйфатлы туклану, бигрәк тә аксымга бай ризык ашау зарур. Көн саен җитәрлек күләмдә физик эшчәнлек булырга тиеш. Яшәгән, эшләгән урыннарда бүлмәләрне җилләтеп торырга кирәк.

Туберкулезны кисәтү өчен күкрәккә флюорография тикшерүе үткәрелә.

Туберкулезны профилактикалау балаларда туган тәүлекләрдә үк башлана. Беренче БЦЖ прививкасы 3-5 тәүлектә эшләнә. Ике айдан балада иммунитет барлыкка килә һәм ул 7 елга бара. Инфекциядән артабан да саклау өчен 7 яшьтә туберкулез пробасы тискәре булган очракта прививка кабатлап эшләнелә. Икейөз ел кулланыла торган бу вакцина максатлы һәм эффектлы булуын күп такырлар дәлилләде.

Прививкалы кеше авырса да, беренче инфекция җиңел үтә һәм актив булмаган стадиясендә билгеле була.

Балаларда һәм яшүсмерләрдә туберкулез авыруын кисәтү өчен ата-аналарга аларның сәламәтлегенә иътибарлы булырга, гаиләдә яшәячәк кешеләрнең сәламәтлеге белән кызыксынырга кирәк. Рентгенофлюорографик тикшеренүләр, бигрәк тә гаиләдә яшь бала булганда, үтеп тору мотлак. Туберкулез белән чирле кеше янында булырга туры килгәндә баланы кичекмәстән врачка күрсәтергә кирәк. Манту пробасы буенча баланың инфекцияле булуы билгеле булганда, табиб-фтизиатрда тикшерү үтү зарур. Балага туберкулезга каршы прививка ясаудан баш тарту – аны инфекциягә каршы тору хокукыннан мәхрүм итү ул. Балагызны сәламәт булу хокукыннан мәхрүм итмәгез.

Вакытында дәвалау учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә һәм дәвалый башлаганда туберклезны җиңеп була. Сәламәт булыгыз!

**Я. ВӘЛИЕВ,**
**республика буенча Роспотребнадзор идарәлеге территориаль бүлегенең 1 разрядлы белгече.**

• ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

# Мөрәҗәгать итүчеләр файдасына эшлибез

Бүгенге көндә илдә мәгълүмат җәмгыяте булдыру чикләрендә дәүләт идарәсе өлкәсенә мәгълүмат технологияләре кертү, шул исәптән электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре күрсәтү, дәвам итә. www.gosuslugi.ru “Дәүләт хезмәтләре” бердәм порталы гражданнарга өйдән чыкмый гына электрон рәвештә гаризалар бирү мөмкинлеген ачты. Андый гаризалар миграция хезмәтендә дә кабул ителә. Портал аша Русия һәм чит ил паспорты рәсмиләштерергә, яшәгән урында, барган урында теркәлергә һәм исәптән төшәргә, төрле белешмә алырга була. Бүлеккә бер тапкыр әзер документ артыннан гына килергә туры киләчәк, документларның оригиналлары күрсәтелгән очракта дәүләт хезмәте бик кыска срокларда башкарыла. Чит ил паспорты артыннан Бөре, Нефтекама яисә Уфа шәһәрләренә ике тапкыр барырга туры киләчәк – документларны илтергә һәм барып алырга. Борай районы миграция хезмәтендә чит ил паспорты рәсмиләштерелми.

2017 елның 1нче гыйнварыннан дәүләт хезмәтләренә 30 процент ташлама кертелде. Ташлама алу өчен, беренчедән, дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза бирегез, икенчедән, дәүләт пошлинасын уңайлы түләү ысулын сайлагыз (банк картасы (MasterCard, Visa, Мир); электрон кошелек (QIWI, Webmoney, Яндекс, Деньги); кесә телефоны (федераль операторлар). Шушы шартларны үтәгәндә, теләсә кайсы дәүләт пошлинасына да ташлама алаласыз. Мәсәлән, Русия паспортын тергезү өчен 1500 сум урынына 1050не генә, чит ил паспорты өчен 3500 сум урынына 2450 сум, халыкара йөртү таныклыгы өчен 2000 сум түгел, 1400не генә түләячәксез. Ташламалар 2019 елның 1нче гыйнварына кадәр гамәлдә булачак.

Дәүләт хезмәтләрендә теркәлү һәм керү өчен парольләрне пенсия идарәлегендә, күпфункцияле үзәктә (Борай авылы, Ленин урамы, 102, цокольле этаж) һәм район хакимиятендә (19 кабинет) алырга була. Бу учреждениеләргә килгәндә паспорт һәм СНИЛСны күрсәтергә кирәк булачак.

**А.ГАТАУЛЛИН,**
**миграция мәсьәләләре буенча бүлек начальнигы.**

• СПОРТ

# Егетләр мәйдан тотты



Февраль башында Тәтешле районында Башкортстан Республикасы мәктәп укучыларының XIX Спартакиадасы кысаларында милли көрәш буенча төбәк ярышлары үтте. Анда Борай районының яшь көрәшчеләре уңышлы чыгыш ясады.

Республиканың җиде районынннан килгән спортчылар тугыз авырлык категориясендә көч сынашты. Борай гимназиясеннән Айнур Муллагалиев–65, Мөнир Зарипов–75, Борай беренче мәктәбеннән Нурислам Гарипов 70 килограммга кадәр авырлык категориясендә җиңүчеләр булды. Урал Камильянов (беренче мәктәп) 60 килограммга кадәр авырлыкта икенче урынны алды. Борай өченче мәктәбеннән Альмир Әхмәтханов (50 килограммга кадәр), беренче мәктәптән Артем Зулманов (55 килограммга кадәр), гимназиядән Илгиз Нурмөхәмәтов (80 килограммнан югары) пьедесталның өченче баскычына күтәрелде. 45 килограммга кадәр авырлык категориясендә көрәшүчеләр арасында Радомир Могыйнов та (өченче мәктәп) яхшы нәтиҗә күрсәтте. Беренче, икенче урыннарны алган көрәшчеләр апрель аенда Уфада үтәчәк республика бәйгеләрендә катнашачак. Спортчылар команда исәбендә өченче урынны яулады.

Яшь көрәшчеләрнең әлеге нәтиҗәләрендә тренер, көрәш буенча спорт мастеры Илгиз Ногмановның да тырышлыгы, балаларны кызыксындыра белүе чагыла. Көрәш буенча күнегүләр Яшьләр үзәгендә даими үтә. Тренер әйтүенчә, егетләр милли спорт төре белән бик кызыксынып шөгыльләнә, ата-аналар да балаларының мавыгуын хуплый, авыллардан килүчеләр дә бар.

Көрәшчеләребезгә республика бәйгеләрендә дә уңышлар телибез.

**Г. МАННАНОВА,**
**балалар-үсмерләр спорт мәктәбе директоры.**

# Ветераннар сынатмый

Спорт белән шөгыльләнеп сәламәтлеген ныгытыйм диючеләргә бертөрле дә каршылык юк. Ачык һавада йөрисең килмәсә, физкультура-сәламәтләндерү үзәге, бассейн, спортзаллар иртәдән кичкә кадәр эшли. Шабай мәктәбендәге спорт залының да ишеге ябулы түгел, биредә баскетбол, волейбол уеннары еш үтә.

Күптән түгел монда районның хөрмәтле хезмәт ветераннарының берсе, элекке Мәгъдән исемендәге колхоз рәисе Вафи Инсаф улы Галиев истәлегенә багышланып традициягә кергән волейбол ярышы булып үтте. Районның спорт ветераннары, Бадрак авылы яшьләре, Шабай балалар йорты командалары, оста уен күрсәтеп, көярмәннәрне сокландырды.

Бадраклылар үткән елгы җиңүне бу юлы да үзләрендә калдыруга иреште. Икенчегә – ветераннар, өченчегә шабайлылар чыкты.

Спорт сөюче ветераннарыбыз хакында аерым тукталасы килә. Команда составындагыларның уртача яше илледән югары булуга карамастан, спортка уңай карашлары, һәр уенчының шәхси осталыгы күп яшьләргә үрнәк булырлык. Мәсәлән, Рәвис Мәкъсүтов, Фидус Мортазин, Илдар Солтанов һәм башкалар – Борайда волейбол уены осталары. Аерым номинацияләрдә ветераннар һәм Бадрактан агалы-энеле Айнур белән Рәмзил Солтановлар макталып әйтелү гаҗәп түгел иде. Бәйгене оештыручы баш судья, Шабай балалар йортының физик культура укытучысы Ришат Шәйнуров аларга истәлекле бүләкләрен тапшырып, киләчәктә дә шулай актив булуларын, сәламәтлек теләде. Беренче урын алган бадраклылар махсус кубокны үзләрендә калдырды. Йомгаклап шуны әйтәсе килә, районда волейбол уенына тагын да байтак өлкәннәрне һәм яшьләрне җәлеп итеп булыр иде. Алдагы көннәрдә мондый ярышларда катнашучы командалар саны артырына ышаныч зур.

**Ф. ӘХМӘТШИН,**
**Шабай балалар йорты тәрбиячесе.**

## Хәтер



9 февраль көнне безнең кадерлебез Абсаликов Айдар Ринат улының арабыздан китүенә бер ел тулды. Аның безне ташлап китүенә күңел әле дә ышанмый. Сине юксынабыз, сагынабыз, искә алмаган бер көнебез дә юк. Безнең белән бергә улыбызны белгән дуслары да искә алыр дип ышанабыз.

Йөрәк әрни, күңел тула,
Күзебездән яшьләр түгелә.
Кайтмассың шул, күпме теләсәк тә,
Юллар ябык инде мәңгегә.

**Сине искә алучы әтиең, әниең, абыең.**

Район мәдәният бүлеге, мәдәният хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы, район мәдәният хезмәткәрләре, Алтаю авыл клубының мәдәни җитәкчесе Шарафутдинова Ириналың сөекле

**ӘНИСЕ**

вафат булу сәбәпле, аның, балаларының, туганнарының авыр кайгыларын уртаклаша.

Администрация сельского поселения Кузбаевский сельсовет, Совет ветеранов выражают искренние соболезнования депутату Совета Ялаловой Дусе, заведующей клубом д. Алтаево Шарафутдиновой Ирине в связи со смертью любимой матери

**ИЛИКБАЕВОЙ Сафии Садиахметовны**

и разделяет боль и горечь тяжелой утраты.

Лаеклы ялдагы хезмәттәшебез Н.С.Дәүләтгәрәеваның сөекле тормыш иптәше

**ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВ Каниф Шакирхан улы**

вафат булу сәбәпле, аның, балаларының, туганнарының авыр кайгыларын уртаклашабыз.

**Балалар иҗат йорты коллективы.**







**КУЕДИНСКИЙ ЛЕСОЗАВОД**
**ДОМА БАНИ ИЗ БРУСА**
сечение 150мм,180мм,200мм.
**КОМПЛЕКТЫ ДОМОВ** от 96000 руб.
Реклама
ЗИМНИЕ ЦЕНЫ на ЛЕТНЕЕ СТРОИТЕЛЬСТВО
Предложение действует до 08 марта 2017года.
Пермский край, п. Куеда, ул. Трактовая,3Б
Тел.: 8(34262) 3-20-70, 8-982-451-23-57,
**8-912-985-67-85**
ИП Сарина М.П. Св. 316595800082911
Наш сайт: www.kuedinskii-lesozavod.ru

В здании ГОСАПТЕКИ № 44 (с. Бураево, ул. Ленина, д. 104/1)
*13 февраля с 11.00 до 12.00 час.*
“РАДУГА ЗВУКОВ”
ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА
**СЛУХОВЫЕ АППАРАТЫ**
(заушные, карманные)
Цена: от 7000 до 12000 руб. ГАРАНТИЯ 1 год
ЦИФРОВЫЕ (пр-ва Дании, Германии, России )
Цена: от 13500 до 17000 руб. *Товар сертифицирован.*
Справки по тел: 8-901-866-81-57(МТС)
Сдайте один старый аппарат и получите скидку при покупке нового 7%*.
*Подробности можно узнать на месте у продавца-консультанта и по телефону.
ОГРН 304183133700096 от 31.03. 2003 г., ИП Вилков В.А.,
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА
РЕКЛАМА




**Пеноблоки, керамзитоблоки.**
Тел.: 8-917-410-32-48.
ИП Тимашев В. Р. св-во: 304026406300232. Реклама

**Такси «Юлдаш»**
Услуги а/м «Нива»
**Тел.: 2-16-16**, 8-937-169-16-16. Св-во: 314028000133892.
ИП Нурмухаметов Р.Р. Реклама

**Такси «Форсаж».**
Выезд по деревням и городам.
**Тел.: 8-937-500-15-15.**
ИП Курбанов С. Ф. Св-во: 310027130500069. Реклама

**Требуются** водители категории ВСДЕ.
Оплата от 2000руб/день, вахта по РБ, оформление по ТК. Тел.: 8-917-800-40-88, 8-917-800-54-84.
ООО “Стройтранс-логистик” ОГРН 1160280061083. Реклама.

# Котлыйбыз!

Сәетбай авылында яшәүче кадерле әтиебез, зур әтиебез, хөрмәтле кодабыз **Нурисламов Камил Төхвәт улын** 85 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз! Әти! Әниебез белән матур тормыш юлын үттегез. Безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле таянычыбыз, киңәшчебез, җылы кояшыбыз, рух чишмәбез син.

Безне яратып үстереп, тормыш юлына аяк бастырдыгыз. Әле булса, әниебез рухын саклап, өй учагын сүндермичә яшәвеңә рәхмәтлебез.

Сиңа сәламәтлек, балаларыңның йөрәк җылысын тоеп, оныкларыңның изгелеген күреп озын гомер кичерүеңне телибез.

*Исән-имин, озын гомерле бул,*
*Балкып торсын корган йортыгыз.*
*Безне шатландырып озак яшә,*
*Иң кадерле безнең кешебез.*

**Сине яратып, Зәйнетдиновалар, Шакировлар, Гыймадиевлар, Нурисламовлар гаиләләре.**

Үләй авылында яшәүче кадерле әниебез, дәү әниебез **Гыйльмиярова Мәһия Гыйзелхан кызын** туган көне – 70 яшьлек юбилее белән кайнар котлыйбыз!

Безнең әниебез 40 ел гомерен балалар укытуга багышлады. Аны эшендә һәрвакыт яраттылар һәм хөрмәт иттеләр.

Әниебез, сиңа сәламәтлек, күңел тынычлыгы, алдагы көннәрдә кайгы-хәсрәт күрми, балаларыңның, оныкларыңның күңел җылысын тоеп, изгелекләрен күреп, туган йортыбызның утын сүндермичә, озын-озак хәерле гомер кичерүеңне телибез.

*Сиңа рәхмәт сүзен, әниебез,*
*Белдерәбез туган көнеңдә.*
*Үстердең син безне кеше итеп,*
*Олы рәхмәт барысы өчен дә.*
*Гомер буе язсын иде безгә,*
*Әни, диеп озак дәшәргә,*
*Кайгы күрми, бәхет-шатлык белән*
*Бергә-бергә озак яшәргә.*

**Иң изге теләкләр белән улларың, киленнәрең, оныкларың.**

Ает авылында яшәүче кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, картәтиебез **Шәмсетдинов Исмак Минәҗ улын** табигатьнең искиткеч бер мизгелендә, бөтен дөнья ап-ак карга төренгәндә 80 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Сиңа җан тынычлыгы, сәламәтлек, бәхет, алдагы көннәреңдә кайгы-хәсрәт күрми, әни белән тигез гомер кичерүегезне телибез!

*Юбилеең белән котлап сине*
*Тәбриклибез ихлас күңелдән.*
*Тигез гомер, бәхет, шатлык –*
*Шул теләкне кабул ит бездән!*

**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, балаларың, киленкиявләрең, оныкларың.**

Кәшкәләү авылында яшәүче кадерле тормыш иптәшем, әниебез, дәү әниебез **Корбанова Зөлфия Нурлыгаян кызын** 55 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән кайнар котлыйбыз!

Сиңа озын гомер, бәхет, шатлыклар, җан тынычлыгы, тән сихәте, саулык-сәламәтлек телибез. Кайгы-хәсрәткә бирешми, балаларыңның һәм оныкларыңның игелеген күреп, озак еллар яшәргә язсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә төренеп яшә, ярдәмчел һәм изге күңелле әниебез.

*Сөйкемле карашың кояшка тиң,*
*Бар тормышны нурга күмәсең,*
*Бу дөньяның барлык хикмәтләрен*
*Бары тик син генә беләсең.*
*Тормышта гел ярдәм итеп тора*
*Зирәк киңәшләрең, җылы сүзең.*
*Иркәлисең, яратасың, юатасың,*
*Тыңлыйсың да, аңлыйсың да үзең.*
*Күңелең синең күтәренке булсын,*
*Сөенеп һәм сөендереп мең-мең яшә.*

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең Радаэль, балаларың Айсылу-Ранис, Рамил-Гөлнара, оныкларың Илназ, Азалия – Рузиль – Ализа һәм Тәнзилә апаң.**

Сөекле әниебез, тормыш иптәшем **Дәүләтбаева Денария Рәфкать кызын** күркәм юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз!

Кадерлебез! Февраль салкыннарында тусаң да, күңелеңнән һәрчак яктылык, нур бөркеп яшисең. Син – гаиләбезнең җылы учагын сүндермичә саклаучыбыз, таянычыбыз, терәгебез.

*Котлы булсын, әни, туган көнең,*
*Озак яшә, бул син бәхетле.*
*Янныбызда син булганда гына*
*Табып була олы бәхетне.*

**Иң изге теләкләр белән балаларың Илиза, Дилара һәм тормыш иптәшең Фәвис.**


**Бурение скважин** под воду до 100 м на базе ЗИЛ-131. Качественно, быстро, гарантия. РАССРОЧКА!!! 8(927)969-43-53, 8(987)493-90-92
ИП Сарварова А.Ш. Св-во: 316028000123041 Реклама

**Магазин «Аксарлак»**
**приглашает Вас за покупками!**
**В продаже широкий**
**ассортимент продуктов питания.**

**С 9 февраля по 12 февраля:**

| | |
|---|---|
| Рыба Минтай с/м, кг | 99,90руб. |
| Масло подсолнечное «Олейна», 1л | 69,90руб. |
| Яйцо 1сорт, 10 штук | 49,90руб. |
| Киви, кг | 99,90руб. |
| Клубника, 250гр | 149,90руб. |
| Чай «Пр. Нури высокогорный» 25 пак. | 29,90руб. |
| Конфеты «Рафаэлло», 150гр | 169,90руб. |
| Открытки-Валентинки | 4,90руб. |
| Набор подарочный (игрушка мишка+ конфеты «Марсианка» 200г) | 199,90руб. |

Ждем Вас по адресам: **с.Бураево, ул.Ленина, 31, ул.Ленина, 130.** ООО «КУРС», св-во: 1140280409257. Реклама

**КУЕДИНСКИЙ ЛЕСОЗАВОД**
**ДОМА БАНИ БЕСЕДКИ**
**из оцилиндрованного бревна**
**от 180мм до 280 мм**
**Принимаем заказы на ЛЕТО по ЗИМНИМ ЦЕНАМ!!!**
**От 7000 р/м³**
**Цены действует до 08 марта 2017 г.**
Пермский край, п. Куеда, ул. Трактовая,3Б
Тел.: 8(34262) 3-20-70, 8-982-451-23-57,
**8-912-985-67-85**
ИП Сарина М.П. Св. 316595800082911
Наш сайт: www.kuedinskii-lesozavod.ru
Реклама

**ООО "Профнастил-Бирск"**
Тел. (34784) 4-06-81, 4-06-68
г.Бирск, ул.Мира,129
Изготовит за сутки:
Профнастил – оцинкованный и окрашенный (настоящий металл 0,5 мм). Для Вас: доборные элементы, пароизоляция и крепеж, черепица "Монтеррей", металлосайдинг "Корабельная доска" – "под дерево" и "камень"! Св-во: 1060257009669 от 01.08.2006. Реклама

ИП Ситдиков А.Р. Св-во: 305021731400014

**Рассрочка на 4 месяца без переплат**

Приемник цифрового ТВ Rolsen RDB-523A
**990 руб.**
**Комп+**
**Большой выбор НОУТБУКОВ ТЕЛЕВИЗОРОВ**

Фото печать
Цветная печать
Ксерокс - 4 руб.
**Установка программного обеспечения**
**Ремонт компьютеров, ноутбуков**
**Антивирусная защита**
**8-960-384-4567**
Салон компьютерной техники "Комп+" рядом с магазином "Кооператор"
Реклама

**ИНДУСТРИЯ ОКОН БУРАЕВО**
**8-937-15-16-373**
**8-987-62-21-851**
**8(34756)2-80-54**
**Зима**
**Сезон больших скидок**
**(на окна,двери,гаражные ворота)**
Реклама
Прием заказов: **с. Бураево, ул. Советская 8 (здание Техно Дом) маг. Полушка(2 этаж). Производство с.Бураево ул.Чкалова 9**
ИП Магрупов св.во № 309027118700021 от 6.07.2009


## Сатыла-продается

Телята. Тел.: 8-906-146-86-01. Реклама

***

**Доски** 30; 40; 50 мм. Комплектуем брусовые дома за один день. **Евровагонка** (Киров) упаковка 2,50м – 540 руб, 2,70 м – 580 руб. Тел.: 8-927-232-64-56. Ул.Коммунистическая, 71. ИП Ханов И. А. св-во: 315028000034681. Реклама

***

Куры-молодки 5-месячные – 250р. Ул. Пионерская,37. Тел.:8-987-616-75-90, 8-927-932-09-00. ИП Зиганшина З.Р. Св-во: 304021709000081. Реклама

***

Пиломатериалы. Доска (береза, хвоя). Комплектуем дома из бруса. Дрова колотые. Доставка. Тел.: 8-987-025-97-77. ИП Садиков Д.Ю. св-во 313028000054435. Реклама

***

Корова, бычки годовалые. Тел.: 8-903-350-66-07, 8-987-093-30-11. Реклама

***

Трубы НКТ, трубы под канаву, трубы под банные печи, профильные трубы 40х20 и др. Угольники, листовое железо, сетка-рабица. Тел.: 8-967-741-11-08. ИП Садиков Д.Ю. Св-во: 313028000054435. Реклама.

***

Куры-молодки красные, белые, пестрые. Комбикорм. ул. Промышленная, 9. Тел.: 8-927-339-71-44, 8-917-372-74-68. ИП Магзумова Р. Н. Св-во: 315028000055417. Реклама

***

## Төрлесеннән-разное

Возьму в аренду помещение под оптовый склад от 200 кв.м. Тел.: 8-987-618-26-86. ИП Сахаутдинов Р.Г. Св-во: 304027617300160. Реклама.

***

Куплю ВАЗ, "Газель", УАЗ, "Ниву", иномарки. Дорого. Тел.: 8-987-015-57-77, 8-937-482-40-06. ИП Емельянов О.В. св-во: 314028000092214. Реклама

***

**Ассенизаторские услуги**: откачка канализаций (шамбо), выезд по деревням. Тел.: 8-937-477-77-97, 8-927-344-71-72. ИП Курбанов С.Ф., св-во: 310027130500069. Реклама

***

Телки, быки от 1 мес. до 2 лет высокоудойных, мясных, симментальских пород. Сено, солома, ячмень, пшеница, комбикорм, сухой жом. Недорого. Доставка бесплатно. Тел.: 8-937-343-80-22, 8-909-345-99-77. КФХ ИП Сираев А. З. ОГРН 312025022700032. Реклама

***

Ремонт холодильников, морозильников, стиральных машин (автомат). Гарантия. Качество. Тел.: 8-927-334-18-25 Марат. ИП Мустафин М. М. Св-во: 311027115700016. Реклама

***

Комплектуем дома из бруса. Обрешетка в подарок. Доставка. Тел.: 8-927-966-33-05. ИП Хабибуллина Г.Я. Св-во: 314028000082204. Реклама.

***

Куплю мотоцикл "Минск" в любом состоянии. Тел.: 8-960-381-10-12. Реклама

***

Закупаем КРС (телки, бычки, коровы) живым весом, дорого. Тел.: 8-961-355-39-99, 8-965-641-26-99, 2-03-37. ИП Шайнуров И.М. св-во: 314028000086267. Реклама

***

Ремонт холодильников, морозильников. Качество, гарантия, выезд. Тел.: 8-927-235-89-89, 8-962-522-40-41. (Фирдавис) ИП Исламов Ф. Ш. св-во: 304021707600044. Реклама

***

АНОО «Специалист» проводит обучение, повышение квалификации по рабочим специальностям газовой и нефтяной промышленности (слесаря, машинисты, операторы, бурильщики) более 100 специальностей. Тел.: 8-905-351-46-66, 8-937-848-69-00. ОГРН 1110200001867, лиц. № 3395 от 25.11.2015 г. Реклама

***

Ищу работу по ремонту и обивке мягкой мебели. Тел.: 8-987-596-77-38. Реклама

***

Всем добра! Прошу откликнуться тех, кто 11.01.2017г. проезжал по участку автодороги Бураево-Старобалтачево. Нужны записи с камер видеорегистраторов. Произошло ДТП. Тел. : 8-963-270-65-83.

***

Евровагонка (Архангельск), ОСП, утеплитель, гипсокартон. Доставка. Строительно-отделочные работы. Тел.: 8-909-347-25-77. ИП Давлетов Р. Л. Св-во: 316028000081106. Реклама


**Такси "Гарант"**
**Тел.: 2-24-24,**
8-927-936-00-24,
8-987-058-07-24.
ИП Бакиров Р.З. Св-во: 314028000071362. Реклама

**Бурение скважин** на воду на базе Зил-131. Тел.: 8-917-405-37-64 (Дюртюли, Флорис).
ИП Идрисов Ф. С. Св-во: 304026023100042. Реклама

**"Спутниковое ТВ"**
Телекарта,Триколор обмен.
Майдан,ТНВ,БСТ,Курай,Туган Тел.
**8-917-378-70-07**
ИП Курбангалиев Р.Р. св-во: 315028000124251.Реклама

РЕСПУБЛИКАНСКИЙ НАРКОЛОГИЧЕСКИЙ ДИСПАНСЕР №1 МЗ РБ
www.alkogolizmufa.ru www.narkolog-rb.ru
**ЗАПОИ. ПОМОЩЬ. АНОНИМНО в т.ч. НА ДОМУ 24ч**
тел. 8-904-737-45-27
8-965-654-67-65
(347) 272-83-09
WhatsApp 89047374527
Лиц. ЛО 0201 002543 от 04.07.2013 г.
Реклама
ВОЗМОЖНЫ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



Учредители: Агентство по печати и средствам массовой информации Республики Башкортостан, Государственное унитарное предприятие Республики Башкортостан Издательский дом «Республика Башкортостан». Общественно-политическая газета "Алга" муниципального района Бураевский район Республики Башкортостан издается с 19 февраля 1930 года. Выходит во вторник и пятницу на татарском языке.

**Алга**

Директор (баш редактор) И.Х.САФИУЛЛИН

Гәзит элемтә һәм киңкүләм коммуникацияләр сферасында күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәтнең Башкортстан Республикасы буенча идарәлегендә 2015 елның 1 сентябрендә теркәлде. Теркәү саны ПИ № ТУ 02-01438. Тиражы 3699 данә. Күләме бер шартлы басма табак. Форматы 4хА3.

Редакциянең адресы: 452960, БР, Борай районы, Борай авылы, Вострецов урамы, 37. Телефоннар: Редактор /факс/ 2-11-81, җаваплы секретарь, хатлар бүлеге 2-13-81, авыл хуҗалыгы бүлеге 2-17-30, бухгалтерия, реклама,котлаулар, белдерүләр /факс/ 2-17-36. E-mail: ALGA@ufamts.ru. Нәшер итүче – «Республика Башкортостан» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесенең адресы: 450079, Башкортстан Республикасы, Уфа шәһәре, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13. Гәзит редакция компьютерында җыелды һәм версткаланды, офсет ысулы белән басылды.

Автор фикере редакция фикере дигән сүз түгел. Редакция мәҗбүри хат алышу алып бармый. Кульязмаларга рецензия ясалмый һәм алар кире кайтарылмый. Имзасыз хатлар каралмый.
**Гәзит басуның сыйфаты өчен типография җаваплы.**

ИНДЕКСЫ 00705. Заказ № 43. Гәзиткә кул кую вакыты – 9 февраль, 16 сәгать. Кул куелды – 15.45 сәгатьтә. Гәзит Бөре мәгълүмат үзәге – «Республика Башкортостан» нәшрият йорты дәүләт унитар предприятиесе филиалында басылды. Адресы: 452450, Бөре шәһәре, Ленин урамы, 56. Телефон: (8-34784 ) 2-25-60.